


# 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне.

# Бәйрәм белән сезне кадерле этиләр!

# алар









Әти янымда булганда

Бер нәрсәдән курыкмыйм мин

Әти сүзе миңа закон,

Әтиемне тыңлыйм мин.





шләмәсә эшләмәсен,

азетын укып торсын,

елевизор карап ятсын,


Әтием генә булсын.

*Әтием белән әнием*

*Иң – иң кадерлеләрем*

*Бергә генә яшәсеннәр*

*Минем шушы теләгем.*




Мин дә әтием шикелле

Шофёр булырга уйлыйм

Шуның өчен һәр вакыт

Машинам белән уйныйм.







**Әтинең киң җилкәсендә**
**Алмаш – тилмәш утырдык**
**Сеңлем әйтә:-Син, әтием,**
**Йөри торган урындык!**



Әти белән урамнан бер
Үтүләре күңелле.
Һәр бала да бу дөньяда
Булсын иде әтиле.



Әти безнең терәгебез ,
Әти безнең яклаучы.
Кирәк чакта минем белән
Дустым кебек уйнаучы .








Әтиләр булса янда,
Безнең өчен горурлык

**Әтиемнең алтын куллары-**
**Имин булсын йөрер юллары**
**,,Әти!” диеп әйтү бер ләззәт**
**Син булганда, әти, бар рәхәт!**



Әти эштән кайтуга,
Чабам аның янына
Сагындым сине, диеп,
Сарылам муенына.





,,Балам” диеп бер дәшүе дә бит
Җылы сала җанга, күңелгә
Кайгыртуың өчен рәхмәт әти
Шулай булсын иде гомергә





Әниләрне иң кадерле дибез,

Әтиләрсез яшәп буламы?


Таба алмам алыштырыр кеше,


Әйләнсәм дә бөтен дөньяны.



Ял көннәрен бергәләп
Үткәрәбез әйбәтләп
Ул бит минем киңәшчем,
Кирәк чакта сердәшчем.











**Кадерле әтиләр! Сезне тагын бер кабат бәйрәмегез белән котлыйбыз, саулык, бәхет телибез!**